КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 апрель г.Казань № 256

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өстенлекле тәртиптә социаль контракт күп балалы гаиләләр белән төзелә.»;

26 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«товар китерүчедән товар китерүне тоткарлау (китерү срокларын өзү, тәэмин итүче тарафыннан товар китерү бурычын үтәмәү).»;

27 пунктның икенче абзацында «24» саннарын «25» саннарына алмаштырырга;

34 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Эшкуарлык компетенцияләрен үстерү өчен укулар уздыру кирәклеге турында карар кабул итү максатларында социаль яклауның территориаль органы билгеләү турында гариза биргән мөрәҗәгать итүчеләрнең, анда әлеге Нигезләмәнең

10 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында каралган чараларны һәм «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясында күрсәтелгән чараларны билгеләп үтеп, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы билгеләгән мәгълүмат системасында эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен тест узуын тәэмин итә.»;

әлеге Нигезләмәнең 1 нчы кушымтасында:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) хезмәткә сәләтле барлык әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) хезмәт эшчәнлеген, индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген йә һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында эшчәнлекне гамәлгә ашыру шартларында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) уртача җан башына кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк.»;

9 пунктта «эшкә урнашкан» сүзләрен «хезмәт эшчәнлеген, шәхси эшкуарлык эшчәнлеген йә һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында эшчәнлекне гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин